РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26» 02 2020 г. №105

Яңа составта
ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты каршындагы
район торак-көнкүреш комиссиясен
раслау турында

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу һәм торак урыннары бирү тәртибен камилләштерү максатларында Башкарма комитет КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы район торак-көнкүреш комиссиясен яңа составта, №1 кушымта нигезендә расларга.

2. №2 кушымта нигезендә, «Район торак-көнкүреш комиссиясе турында» Нигезләмәне расларга.

3. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 февралендәге 56 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР ЮМР Башкарма комитеты
Җитәкчесе А. Ә. Шафигуллин

Н.А. Әбилтарова
2-76-81

Кушымта №1
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
Карарына
« 26» 02 2020 ел №105

Район торак-көнкүреш комиссиясе составы.

| | |
|---|---|
| Шафигуллин А.Ә. – | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Самонина С. П. - | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Әбилтарова Н.А. - | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге начальнигы, комиссия секретаре: |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Шәрипов Р. Ә. - | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Якупов Р. М. - | юридик бүлек башлыгы; |
| Хәмидуллин Л. А. - | полиция өлкән лейтенанты, Ютазы районы буенча Эчке эшләр министрлыгының НЭБ һәм ПК өлкән оперуполномоченные (килешү буенча); |
| Огнева Е. С. - | район башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Галләмова Р. А. - | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Шәрифуллин В.А.- | инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Шуть А. Р. - | « Техник инвентарьлаштыру бюросы» Республика дәүләт унитар предприятиесенең №11 районара филиалының Ютазы төркеме җитәкчесе (килешү буенча); |
| Рәшитова З. Ә. - | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча). |

Кушымта №2
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
Карарына
« 26» 02 2020 ел №105

**«Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак-көнкүреш комиссиясе турында»**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Торак-көнкүреш комиссиясе Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән төзелә.

1.2. Комиссия составы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

1.3. Торак-көнкүреш комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы торак законнарына, башка норматив һәм хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Торак-көнкүреш комиссиясенең төп бурычлары

Торак-көнкүреш комиссиясенең төп бурычлары булып тора:

2.1. Социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен гражданнар гаризаларын карау;

2.2. «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль найм шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу турында карар чыгару өчен кирәкле гаризага теркәлгән документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

2.3. Социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алудан баш тарту турында карарлар әзерләү;

2.4. Гражданнарның исәпкә алу турында гаризаларын теркәү Кенәгәсен, социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алынган гражданнарны исәпкә алу кенәгәсен, законнар нигезендә исәпкә алынган гражданнарның исәпкә алу эшләрен тутыру һәм алып бару дөреслеген контрольдә тоту;

## 3. Торак-көнкүреш комиссиясе составы

Торак-көнкүреш комиссиясе составына җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Торак-көнкүреш комиссиясенә рәис җитәкчелек итә. Торак-көнкүреш комиссиясе рәисе булмаганда, аның бурычлары комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

Кворум өчен торак-көнкүреш комиссиясе составының әгъзалар саны так булырга, әмма кимендә 5 (биш) кеше булырга тиеш.

## 4. Торак-көнкүреш комиссиясе эшчәнлеген оештыру

4.1. Торак-көнкүреш комиссиясе рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

4.2. Торак-көнкүреш комиссиясе утырышлары расланган план нигезендә, әмма айга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышлар, әгәр анда иҗтимагый торак комиссиясе әгъзаларының 50%тан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

4.3. Җирле үзидарә органнары яисә юридик зат тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи зат гражданнарны исәпкә алу мәсьәләсен карау өчен кирәкле документларны әзерли.

4.4. Торак булдыру өчен гражданнарны исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) буенча торак-көнкүреш комиссиясе утырышында каралган сораулар иҗтимагый торак комиссияләре утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.5. Иҗтимагый торак комиссиясе карары, утырышта катнашучыларның күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Торак-көнкүреш комиссиясе карары тәкъдим итү характерына ия.

4.6. Торак-көнкүреш комиссиясе карарын исәпкә алып, Башкарма комитет җитәкчесе белән гражданнарны исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) турында күрсәтмә, гаиләне исәпкә алудан төшерү турында күрсәтмә әзерлиләр.

4.7. Җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи зат, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләр реестрын төзи, аны Башкарма комитет җитәкчесе белән раслый.

4.8. Торак-көнкүреш комиссиясе, законнар нигезендә, торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлекләрен формалаштыру, алып бару, аларның дөреслеген контрольдә тоту эшендә катнаша.

4.9. Торак-көнкүреш комиссиясе торак шартларын яхшырту өчен законнар нигезендә гариза биргән мөрәҗәгать итүчеләрне ел саен (киләсе елның 1 апреленә кадәр) яңадан теркәүдә катнаша.

## 5. Иҗтимагый торак комиссияләренең җаваплылыгы

Иҗтимагый торак комиссиясе әгъзалары реестрны формалаштыру, исәп эшләрен алып бару һәм гамәлдәге законнар нигезендә торак шартларын яхшырту өчен гаиләләрнең локаль исемлекләрен тәртиптә тоту буенча җаваплы.